# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлегенең Келәр торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**2025 елның 19 ноябре** **№1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Уставының 26 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Келәр торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Келәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары урнаштыру, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чар урыннарын юкка чыгару.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы ав., Үзәк ур., 4 й.
- ТР, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай ур., 16 йорт, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгән көннән алып 10 (ун) көн эчендә урнаштырырга.

Кама Тамагы муниципаль районының<br>
Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы,<br>
халык җыенында рәислек итүче Э.М. Мөхәммәтшин